ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

16.11.2022

Казан ш.

**КАРАР**

№ 494-84/тэ-2022

«Казан милли тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-42/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җайга салынулы оешманың кирәкле планлаштырылган тулай табышын тәгаенләштереп, 2023 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Казан милли тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык

энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 23.11.2018 № 5-42/тэ карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 5-27/тэ, 11.11.2020 № 218-25/тэ-2020, 03.11.2021 № 195-22/тэ-2021 карарлары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына, яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан милли тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-42/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү турында» 03.11.2021 № 195-22/тэ-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.11.2018 № 5-42/тэ
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2022 № 494-84/тэ-2022
карары редакциясендә)

## 2019-2023 елларга «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Казан милли тикшеренү технологик университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1352,41 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1376,20 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1376,20 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1409,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1409,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1464,66 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1464,66 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1523,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап | 1622,24 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2023 кадәр | | | | | | |
| 1.2 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1622,89 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1651,44 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1651,44 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1691,90 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1691,90 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1757,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1757,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1827,89 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1946,69 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге